| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 21 апреле Кукмара ш. № 55

«2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Кукмара муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән Кукмара муниципаль районы бюджетына 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына кертелгән үзгәрешләрне карап, Кукмара муниципаль районы Советы карар **бирде:**

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2021 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1 420 986 763,16 сум;

2) Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 455 154 256,31 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгы (профициты) 34 167 493,15 сум күләмендә

2. Кукмара муниципаль районы бюджетының 2022 елга һәм 2023 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең 2022 елга фаразлана торган гомуми күләмен 1 419 132 957,35 сум һәм 2023 елга 1 419 773 237,79 сум күләмендә;

2) Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2022 елга 1 419 132 957,35 сум һәм 2023 елга 1 419 773 237,79 сум күләмендә;

3) Кукмара муниципаль районының 2022 елга бюджет дефициты (профициты) 0 сум, 2023 елга 0 сум күләмендә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2021 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2022 елга һәм 2023 елга әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә».

1) 2021 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

2) 2020 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

3) 2020 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

4) 2020 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне карарга **4 нче кушымта** нигезендә үзгәртергә.

5) 2020 елга **Кукмара муниципаль районы** чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга **5 нче кушымта** нигезендә үзгәртергә.

6) 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлекләр бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертларны әлеге карарга **6 нчы кушымта** нигезендә үзгәртергә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев